| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ<br>БАВЛИНСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>БАУЛЫ<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |
| --- | --- |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

24.04.2025 ел Баулы шәһәре № 50

Баулы муниципаль районы Башкарма комитетының «Хезмәт хакы Бердәм тариф челтәре нигезендә исәпләнә торган Баулы муниципаль учреждениеләре хезмәткәрләренең хезмәт хакын арттыру турында» 22.06.2011 елның 22 июнендәге 134 номерлы карарына үзгәреш кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт учреждениеләрендә хезмәт хакы Бердәм тариф челтәре нигезендә исәпләнә торган хезмәткәрләрнең хезмәт хакын арттыру турында» 2011 елның 14 июнендәге 477 номерлы карарына үзгәреш кертү хакында» 2025 елның 17 апрелендәге 241 номерлы карары нигезендә, Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Баулы муниципаль районы Башкарма комитетының «Хезмәт хакы Бердәм тариф челтәре нигезендә исәпләнә торган Баулы муниципаль учреждениеләре хезмәткәрләренең хезмәт хакын арттыру турында» 2011 елның 22 июнендәге 134 номерлы карарына (Баулы муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең 10.12.2012 №281, 24.10.2013 №252, 22.01.2014 №18, 31.10.2014 №330, 20.11.2015 №319, 08.07.2016 №219, 10.08.2017 №350, 15.01.2018 №11, 06.12.2021 №213, 30.12.2022 №282, 04.06.2024 №81, 07.11.2024 №153 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

күрсәтелгән карарга 1 нче кушымтаны яңа редакциядә бәян итәргә (кушымта итеп бирелә).

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http://www.pravo.tatarstan.ru) һәм Баулы муниципаль районы сайтында (http://www.bavly.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карар 2025 елның 1 маеннан үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Баулы муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча беренче урынбасарына йөкләргә.

Баулы муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе Д.Л. Бакиров

Баулы муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесенең
2011 елның 22 июнендәге
134 номерлы карарына
1 нче кушымта

(Баулы муниципаль районы
Башкарма комитетының
2025 елның 24 апрелендәге
50 номерлы карары редакциясендә)

Баулы муниципаль районы бюджет өлкәсе хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү буенча бердәм тариф челтәренең тариф коэффициентлары һәм тариф ставкалары (окладлары)

| Бердәм тариф челтәренең түләү разрядлары | Тариф коэффициентлары | Тариф ставкалары (окладлар), сумнарда |
|---|---|---|
| 1 | 1,0 | 23 320 |
| 2 | 1,0114 | 23 586 |
| 3 | 1,0233 | 23 863 |
| 4 | 1,0346 | 24 127 |
| 5 | 1,0473 | 24 423 |
| 6 | 1,0595 | 24 707 |
| 7 | 1,0728 | 25 017 |
| 8 | 1,0855 | 25 314 |
| 9 | 1,0983 | 25 612 |
| 10 | 1,1119 | 25 929 |
| 11 | 1,1251 | 26 237 |
| 12 | 1,1393 | 26 568 |
| 13 | 1,1535 | 26 899 |
| 14 | 1,1675 | 27 226 |
| 15 | 1,1823 | 27 573 |
| 16 | 1,1973 | 27 921 |
| 17 | 1,2124 | 28 273 |
| 18 | 1,2280 | 28 637 |

Искәрмә: җитәкче урынбасарының тариф ставкасы (окладысы) күләме тиешле җитәкченең тариф ставкасыннан (окладыннан) 1 - 2 разрядка түбәнрәк билгеләнә.